ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 18 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 482-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 18 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 482-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 19 октябре
№ 2168-VI ДС

проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 18 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре турында» 2003 елның 11 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 өлешенең «в» пунктчасына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2007, № 10), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«в) квалификация комиссиясе әгъзасы Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыкканда;».

**2 статья**

Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 18 статьясындагы 8 өлешенең 1 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), «комиссия әгъзасының Россия Федерациясе гражданлыгы бетерелгәндә, ул чит ил гражданлыгы (подданлыгы) алганда» сүзләрен «комиссия әгъзасы Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыкканда яисә ул чит ил гражданлыгы (подданлыгы) алганда» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 18 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

Закон проекты Татарстан Республикасы Сайлау кодексының һәм «Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре турында» 2003 елның 11 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләрен «Россия Федерациясе аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 31 июлендәге 407-ФЗ номерлы Федераль законга (алга таба – 407-ФЗ номерлы Федераль закон) туры китерүгә юнәлдерелгән.

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда һәм башка законнарда кулланыла торган төшенчәләр аппараты 407-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе гражданлыгы хакындагы законнарда кулланыла торган терминологиягә туры китерелә: әлеге федераль законнарда «Россия Федерациясе гражданлыгы бетерелү» сүзләре «Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыгу» сүзләренә алмаштырыла.

Шуңа бәйле рәвештә, закон проектында шундый ук үзгәрешләрне Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм «Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законына кертү карала.

**«Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 18 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 18 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башкаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 18 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 18 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнарны таләп итмәячәк.